Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№15 (108)
22 май 2014 ел



# Яңа үзгәрешләр чоры

21 май көнне КФУда чираттагы Гыйльми совет утырышы булып узды. Аны ректор И.Гафуров җитәкләде. Утырыш кысаларында КФУның Экология һәм география институты структурасында булачак үзгәрешләр расланды. Әлеге институт Экология һәм табигать ресурсларын файдалану институтына үзгәртеләчәк. Утырышта КФУның Фәлсәфә факультеты һәм Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтын берләштерү тәкъдиме дә кабул ителде. Әлегә булачак институтның төгәл исеме юк. Әмма аның төзелеше инде билгеле: яңа берләшкән институт фәлсәфә һәм диннәрне өйрәнү, иҗтимагый-сәяси фәннәр, гаммәви коммуникация бүлекләреннән торачак.

## • Вакыйгалар эзеннән

Узган атнада Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтында А.М.Бутлеров ис. Химия институты белән берлектә «Скважиналарны беркеткәндә тампонаж эретмәләр» яңа программасы буенча Казахстан бораулау предприятиеләренең җитәкчеләре һәм белгечләре өчен дисциплинаара квалификация күтәрү курслары булды. «МН Industry» Җаваплылыгы Чикләнгән Ширкәтенең генераль директоры **Т.АДЖИБАЕВ** җитәкчелегендәге **9 КЕШЕЛЕК ДЕЛЕГАЦИЯ** университетыбызның кайбер структур бүлекчәләренә **ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Очрашу барышында фәнни өлкәдә үзара хезмәттәшлек булдыру кирәклеге турында сөйләштеләр.

• • • •

Шушы көннәрдә Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты директоры Р.Хәйретдинов җитәкчелегендәге делегация **СИМФЕРОПОЛЬ, ЯЛТА** һәм **БАКЧАСАРАЙГА** командировкасын тәгалләп, Казанга кайтты. КФУ вәкилләре кырымтатар халкы, әрмән, болгар, грек, Кырым алманнары этник төркемнәре депортациясе корбаннарының 70 еллыгына багышлап үткәрелгән **«ЗАМАННЫҢ СОЦИАЛЬ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ»** V халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашты. Нәтиҗәдә хезмәттәшлек турындагы 6 килешү һәм протоколга кул куелды.

• • • •

17 **МАЙ** көнне УНИКСта **«ДӨНЬЯ МӘРҖӘНЕ – 2014» V ХАЛЫКАРА МАТУРЛЫК ҺӘМ СӘЛӘТ КОНКУРСЫ БУЛДЫ**. Ярышта Азәрбайҗан, Бенин, Бразилия, Һиндстан, Казахстан, Кытай, Кыргызстан, Нигерия, Россия, Төркмәнстан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Швейцария, Көньяк Корея һәм Ямайка вәкилләре булган 15 студент кыз үз илен тәкъдир итте. Алар арасында 8 КФУ студенты да бар иде. Кызлар, өч төрле сынау аша үтеп, үзләрен күрсәтте. Нәтиҗәдә Мисс-Дөнья мәрҗәне исеменә Үзбәкстаннан килгән студент Надира Корбанова лаек булды. Вице-мисс-Дөнья мәрҗәне исемен КФУ студенты Ли Гахён (Көньяк Корея) яулады.

• • • •

19 **МАЙ КӨННЕ** Тольятти шәһәрендә **XXII «РОССИЯ СТУДЕНТЛАР ЯЗЫ»** фестиваленең **ЯБЫЛУ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ**. КФУның иҗат коллективы уку йорты данын лаеклы дәрәҗәдә яклады һәм төрле номинацияләрдә күпсанлы бүләкләргә иреште.

• • • •

Узган елларда студентларның **«ЧИКЛӘРСЕЗ ФӘЛСӘФӘ»** дип аталган слёты булды. КФУ студентлары чакыруы буенча, Казанга Новосибирск дәүләт университетының фәлсәфә факультеты студентлары делегациясе килде. Чараның төп максаты – уку программалары, студентлар фәнни җәмгыятьләре эшчәнлеген тормышка ашыруда тәҗрибә алмашу, фәлсәфә белеме бирүнең мөһим мәсьәләләре буенча фикер алышу. Слёт көннәрендә КФУның фәлсәфә факультеты укытучылары заманча социаль фәлсәфәнең актуаль мәсьәләләрен үзәккә куйган мастер-класслар уздырды. Студентлар исә «Тере идея» фотоконкурсы нәтиҗәләре буенча фотогалерея оештырды.

• • • •

Шушы көннәрдә **«ТАТАР ӘЛИФБАСЫ. КҮПМИЛЛӘТЛЕЛЕК ПРОСТРАНСТВОСЫНДА МИЛЛИ ӘЛИФБА КИТАБЫ (XIX ГАСЫР АХЫРЫ, XXI ГАСЫР БАШЫ)»** исемле китап дөньяга чыкты. Аның авторлары – КФУның историография һәм источниковедение кафедрасы мөдире, тарих фәннәре докторы **А.САЛЬНИКОВА** һәм тарих фәннәре кандидаты **Д.ГАЛИУЛЛИНА**. Китап татар әлифбасын Казан губернасы, совет Татарстаны һәм постсовет Татарстанының күп этник һәм күп милләтле мөхиттә файдаланыла торган мәдәни феномен буларак өйрәнүгә багышланган.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Ректорат

# Нәтиҗәле җыелыш

21 май көнне И.Гафуров җитәкчелегендә ректоратның чираттагы утырышы булды.

Беренче булып Уку-укыту эшләре буенча проректор Р.Минзарипов университетта булачак структур үзгәрешләр турында сөйләде. Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты белән Фәлсәфә факультетын берләштерү көтелә. Яңа структур бүлекнең төгәл исеме әле билгеләнмәгән. Бу мәсьәләне коллектив хезмәткәрләре бергә җыелып хәл итәчәк. Яңа «институт» өч бүлектән торачак: фәлсәфә һәм дин белеменә кереш, социаль һәм сәяси фәннәр, массакүләм коммуникацияләр. Яңа структураның


Влад Михневский фотосы

җитәкчесе итеп профессор М.Щелкунов кандидатурасы тәкъдим ителде. Алга таба Экология һәм география институты директоры С.Селивановская үзенең институтында булачак үзгәрешләр турында мәгълүмат җиткерде. Экология һәм табигать ресурсларын файдалану институты дип исемләнгән структура ике бүлектән торачак. Хәзерге вакытта аның составында булган дүрт кафедра Идарә һәм территориаль үсеш институтына китәчәк, ә Фундаменталь медицина һәм биология институтының бер кафедрасы, киресенчә, аларга кушылачак. Юридик факультет деканы И.Тарханов интеллектуаль хокукларны яклау фәнни-укыту үзәген булдыру идеясе белән чыкты. Җитәкче әлеге үзәкнең максат-бурычлары, эш принцибы, кадрлар составы, эшчәнлек төрләре белән таныштырды. Алда әйтелгән һәр үзгәрешне ректорат вәкилләре бертавыштан кабул итте. Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты директоры И.Галиев КФУ лицеистлары өчен спорт түгәрәкләре һәм секцияләре булдыру турында сөйләде. Аның сүзләренчә, алар инде алдагы уку елында ук ,эшләп китәчәк. И.Гафуров фикеренчә, бу эшкә студентларны җәлеп итәргә кирәк. «Бу алар өчен менә дигән тәҗрибә дә булачак», – дип белдерде җитәкче

• Уртак җиңү

# Чебешне язын да саныйлар

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Җиһанда май. Димәк, тиздән студентлар өчен иң кызу чак җитәчәк: алда аларны сессия көтә. Әлеге зур сынаулар алдыннан, уку елына нәтиҗә ясау рәвешендә, КФУда, гадәттәгечә, иң-иңнәрне билгеләп үттеләр. 20 май көнне төп бинаның Актлар залында «КФУның иң яхшы академик төркеме» конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды.

Әлеге конкурс матур гадәт буенча инде тугызынчы тапкыр үткәрелә. Быелгы ярышка тагын ике яңа номинация өстәлде: кече һәм өлкән курс академик төркемнәренең иң яхшы старосталарын да бүләкләделәр. Әмма, җиңүгә ирешкәнче, катнашучыларга җитди сынаулар аша үтәргә туры килгән.

Бүләкләү тантанасын КФУның уку-укыту эшләре буенча проректоры Р.Г.Минзарипов ачып җибәрде. «Әлеге чара елга нәтиҗә ясый. Елны коллективларны бәяләү белән төгәлләү үзенә бер төрле символик мәгънәгә ия. Ник дигәндә, күмәк җиңү шәхси җиңүгә караганда күпкә кадерлерәк була».

Конкурс кысаларында академик төркем кураторлары да игътибарсыз калмады. Быелгы «Ел кураторы» җиңүчеләре дип Яшел Үзән филиалының математика һәм механика кафедрасы доценты Зөлфия Вахидова, А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтының неорганик химия кафедрасы доценты Юлия Журавлева, Экология һәм география институтының география һәм экология белеме теориясе һәм методикасы кафедрасы ассистенты Рөстәм Фәрхуллин, Идарә һәм территориаль үсеш институтының икътисад, бизнес һәм финанслар өлкәсендә чит телләр кафедрасы доценты Гөлнара Калганова һәм территориаль икътисад кафедрасы доценты Ирина Мальганова, Психология һәм мәгариф институтының гомуми һәм социаль педагогика кафедрасы доценты Ләйсән Рыбакова табылды. Аларга диплом һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

«Кече курс академик төркеменең иң яхшы старостасы» номинациясендә Психология һәм мәгариф институты студенты Миләүшә Төхвәтуллова җиңү яулады. Өлкән курс старосталары арасында исә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты академик төркеме әйдаманы Лилия Якупова җиңде. Җиңүчеләр Санкт-Петербург шәһәренә экскурсиягә сертификат белән бүләкләнде.

Чарада конкурсның төп – «КФУның иң яхшы академик төркеме» – номинациясе җиңүчеләре һәм призерлары да билгеле булды. Беренче курслар арасында А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтының 07-302 төркеме җиңүгә иреште. Кече курс академик төркемнәре арасында исә беренчелекне Идарә һәм территориаль үсеш институтының 14-122 төркем студентлары яулады. Өлкән курсларда исә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 10.2-004 төркеме иң-иң булып танылды. Җиңүчеләр, кураторлары белән бергәләп, җәйге каникул вакытында Санкт-Петербург шәһәренә сәяхәт кылачак.


Влад Михневский фотосы

• Чара

# Яңа юнәлеш – зур уңышлар!

**Динә МӨХТӘСИПОВА**


Влад Михневский фотосы

20 май көнне «КФУда Конкурентлыкка сәләтлелекне үстерү программасында инженерия» темасына багышланган ректор семинары узды.

Чарада КФУ ректоры И.Гафуров, Кырым дәүләт инженер-педагогика университеты ректоры Февзи Якупов, КФУ галимнәре һәм җөмһүриятебезнең төрле сәнәгать вәкилләре катнашты.

«Теге яки бу производствоны оештыру белән бәйле юнәлешләр безнең уку йортында да үсеш алса, яхшы булыр иде. Университет һәрвакыт фундаменталь фәннәр өлкәсе буенча тикшеренүләр уздырган һәм югары нәтиҗәләргә ирешкән. Безгә дә алга барырга, яңа ачышлар ясарга кирәк. Казан һәм республика халкы кыска гына вакыт эчендә университетның уңай нәтиҗәләрен күрергә тиеш», диде И.Гафуров.

Заманча университетның үсеше технологияләр трансферын, фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерүне күз уңында тота. Трансфер һәм технологияләрне коммерцияләштерү бүлеге җитәкчесе Ю.Воробьев КФУның бу юнәлештә үсеш юлын тәкъдир итте. Технологияләр трансферы үзәге эшчәнлеге белән дә таныштырды.

Семинарның икенче өлешендә уку йортының инженер проектларын тәкъдир иттеләр. Эшләнмәләр OpenLab проекты кебек күрсәтелде. «Авыр кара алтынны табу, транспортировка һәм эшкәртү» проектында дүрт эшләнмә тәкъдир ителде. «Полимер материалларны һәм әйберләрне табуда инновацион технологияләр» проектында да берничә эшләнмә бар иде.

Семинарда катнашучылар игътибарына тәкъдим ителгән эшләнмәләр Казан университеты галимнәре хезмәте генә түгел, ә бик күп оешмалар белән башкарылган уртак эш нәтиҗәсе дә.

• Мөнбәр

# «Бәллүр каләм»ле «Дарелфөнүн»

19 май көнне республика журналистлары арасында уздырылган XVII «Бәллүр каләм – Хрустальное перо» конкурсының йомгаклау тантанасы узды.


Влад Михневский фотосы

Татарстан Республикасында 1999 елдан бирле 19 майда Матбугат көне үткәрелә. Чарада катнашкан ТР Дәүләт Советы рәисе Ф.Мөхәммәтшин: «Бүген сезгә рәхмәт әйтә торган көн. Татарстанда барлыгы 7 меңләп журналист бар. Без сезнең эшчәнлекне күреп, белеп, кайчакта тәнкыйтьләп, сезнең белән бер тормыш кичерәбез. 1998 елда, без Татарстанның Матбугат көнен билгеләп үтәргә карар кылып, бик дөрес эшләгәнбез. Сезнең эшегез бик авыр һәм четерекле. Каләмегез тутыкмасын, карасы бер вакытта да кипмәсен», – диде.

Быелгы «Бәллүр каләм» бәйгесенә 5 меңләп эш тапшырылган. Журналистлар 14 номинациядә иҗади көч сынашты. Аларның эшләренә «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры И.Әминов рәислегендәге жюри бәя бирде.

Конкурстан безнең редакция дә читтә калмады. «Дарелфөнүн» газетасы «Татарстан Республикасында чыга торган корпоратив һәм махсуслашкан массакүләм мәгълүмат чаралары» номинациясендә җиңүгә лаек булды. Бу газетабыз өчен – зур дәрәҗә. Аның мондый уңышка ирешүендә уку йортыбыздагы һәр укытучының, һәр студентның өлеше бар.

• Юбиляр

# Олуг остазыбыз Сез!

**Ильмира КАМАЕВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Университетта укыганда һәр студентның яраткан остазы була. Хатыйп абый Миңнегулов бөтен студентлар өчен дә яраткан укытучыдыр, минемчә. Университет коридорында очраса, әллә кайдан сине танып, биргән сәламеңне ала, хәлләреңне белешә. Дәресләре дә кызыклы, мавыктыргыч үтә аның.



Мәктәп елларында дәреслек авторы буларак истә калган **Хатыйп Миңнегулов** университеткә килгәч яраткан укытучыбызы Хатыйп абыйга әйләнде. Студентлар аны борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты тарихын мавыктыргыч итеп, һәр сүзнең тәмен белеп аңлата белгәне өчен генә түгел, изге күңелле, шат йөзле, ихлас булганы өчен дә хөрмәт итә.

Хатыйп Миңнегулов 1939 елның 12 маенда Татарстанның Зәй районы Апач авылында дөньяга килә. Әтисе ягыннан Хатыйп абый морзалар нәселенә барып тоташа. Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы алар гаиләсен дә читләтеп үтми. Әтисе Йосыф (1909-1944) фронтта һәлак була. Әниләре дүрт бала белән тол кала. «Әнкәй безнең өчен гадәти ана гына түгел, ата да, президент та, политбюро да, прокурор да булды. Аның һәр сүзе, һәр ым-карашы безнең өчен катгый закон иде. Әнкәй безне гаять кыен елларда да ашатты, киендерде, үстерде, укытты, тәрбияләде», – дип хөрмәт белән искә ала Хатыйп абый газиз әнисен.

Хатыйп абый башлангыч белемне 1946-1950 елларда туган авылында ала. Аннан күршедәге Пидәр (Федоровка) мәктәбендә укый. Җиденче сыйныфны төгәлләгәч, бер ел колхозда эшли. Аннан 25 км ераклыктагы Сарман районы Иске Кәшер урта мәктәбендә белем ала. 1957 елда, өлгергәнлек аттестаты алгач, ике ел вакыт башта Таҗикстанның Ленинабад өлкәсендә заводта, мамык җыюда, аннан туган авылында колхозчы, клуб мөдире булып эшли. 1959-1964 елларда ул Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. 1962-1963 уку елында, читтән торып укуга күчеп, Пенза өлкәсенең хәзерге Белинский (Чембар) районы Качкару авылында балалар укыта. Университетны тәмамлагач, Сарман районында ике ел Чукмарлы мәктәбе директоры, колхозның партоешма сәркатибе, аннан ел ярым КПССның район комитетында партия мәгарифе кабинеты мөдире булып эшли. 1967 елның ноябрендә исә ул кабат Казан университетына кайта. Бу юлы инде татар әдәбияты кафедрасы укытучысы ролендә. 1972 елда XIV гасыр төрки-татар шагыйре Сәйф Сараи иҗатын өйрәнүгә багышланган кандидатлык, 1991елда «Татар әдәбияты һәм Шәрык классикасы (Үзара бәйләнешләр һәм поэтика мәсьәләләре)» темасына докторлык диссертацияләре яклый. 1980 елда – доцент, 1992 елда профессор дәрәҗәләрен ала. 1984-1989 елларда филология факультетында декан урынбасары булып тора. 1999 елда Хатыйп абыйны татар әдәбияты кафедрасы мөдире итеп билгелиләр. Бүгенге көндә дә Хатыйп абый, Аллага шөкер, университетта студентларга төпле белем бирү эшендә.

Хатыйп абыйның дәрәҗәле исемнәре, төрле бүләкләре күп. Русия Гуманитар фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (академигы, 1996), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1994), фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт бүләге лауреаты (1995), Халыкара ел кешесе (Англия, Кембридж, 1998), Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләге лауреаты (2005), К.Гали исемендәге халыкара премия лауреаты (1998) кебек мактаулы исемнәреннән тыш аның хезмәттәшләре, студентлар арасында ОЛУГ ОСТАЗ дигән хөрмәтле исеме бар. Укытучы кеше өчен моннан да зуррак исем була алмый торгандыр ул.

Хатыйп абый шушы көннәрдә 75 яшьлек юбилеен каршылый. Инде гомер көзләренә атлап барса да, һич тә картаерга ашыкмый ул. Матурлыкка, якты хыялларга омтылып яши белгәнгәдер, күңеле белән һаман яшь. Саекмас көч, сүнмәс дәрт аңа хезмәттәшләре, дуслары, якыннары, укучылары аша күчә торгандыр. Хөрмәтле Хатыйп абый! Юбилеегыз котлы булсын! Сезгә киләчәктә дә тән сихәтлеге, чиксез сөенечләр, гаилә иминлеге, иҗади уңышлар телибез! Һәрвакыт шундый көләч йөзле, яраткан укытучы булып калыгыз! Рәхмәт Сезгә!

Туган көн – узылган юлны хыялда барлау, үткән һәм киләчәк арасында чик сызыгын билгеләү вакыты. Кемнәрдер аны үсешкә күпер һәм чираттагы хыялга караш дип тә билгели. Хыял никадәр масштаблырак һәм мавыктыргычрак булса, ул шулкадәр яктырак булачак һәм тормыш юлын да озаграк яктыртачак.

# Лаеклы тормыш юлы

**Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ,** Укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы җитәкчесе, профессор



Шушы көннәрдә уку йортыбызда эшләүче, аны камилләштерү һәм үстерү өчен күп көч куючы Вузга кадәрле, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры, үз эшенең чын остасы **Людмила Ногманова** гомер бәйрәмен каршылый.

Л.Ногманова карьера баскычының барлык этапларын да уңышлы гына үтеп чыга: укытучы – директор урынбасары – белем бирү оешмасы директоры – белем бирү муниципаль идарә органы җитәкчесе – Мәгариф һәм фән министры урынбасары. Бүгенге көндә ул КФУ җитәкчеләре командасы составында ректор киңәшчесе һәм Психология һәм мәгариф институтының укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы профессоры вазифасында хезмәт юлын уңышлы гына дәвам итә. Карьера белән генә чикләнеп калмыйча, ул хатынкыз бәхетен дә тулысы белән татый. Үрнәк булырлык гаиләсе – яратучы ир, ике бала һәм өч онык – Людмила ханымны мәгариф өлкәсендә фидакарь хезмәт итүгә илһамландыручылар.

Күп елларга сузылган фәнни эзләнүләр, белем бирү өлкәсендәге тәҗрибә, педагогик кадрларның һөнәри үсешенә керткән бәяләп бетергесез өлеше, кешелеклелекнең югары дәрәҗәсе Людмила ханымга хезмәттәшләре һәм ТР, РФнең педагогик берләшмә кешеләре арасында югары дәрәҗә һәм зур ихтирам яуларга ярдәм итә. Аның фәнни казанышлары арасында өч җитди монография, дүрт методик әсбап, Россия педагогик журналларында басылып чыккан 150дән артык мәкалә бар.

• Бездә кунак бар

# Телнең үсеш юллары

**Ренат МИНИГАЛИЕВ**

16 майда Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында РФнең Мәгариф һәм фән министры урынбасары Александр Климов булды. Ул телгә өйрәтүнең торышы, бу өлкәдәге яңа төр методикалар һәм инновацион проектлар белән танышу өчен килде.



Влад Михневский фотосы

Мөхтәрәм кунакны институт директоры Р.Р.Җамалетдинов, уку-укыту эшләре буенча проректор Р.Г.Минзарипов, Вузга кадәрле, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры Л.Н.Ногманова озатып йөрде.

Институтның халыкара эшчәнлек буенча директор урынбасары Г.В.Садыйкова очрашуны яңа төр технологияләр белән җиһазландырылган телгә өйрәтү кабинетлары белән таныштырудан башлап җибәрде. Министр урынбасары туган телгә интерактив элемтә аша дистанцион, инстутут укытучыларын инглиз теленә өйрәтү, чит тел буларак рус һәм татар телләрен кичке курсларда укыту кебек проектлар белән кызыксынды.

Укыту кабинетлары белән танышып чыкканнан соң, әңгәмә «Ана теле» үзәгендә дәвам итте. Аның җитәкчесе К.С.Фәтхуллова татар теленә өйрәтү онлайн мәктәбе проектын гамәлгә ашыру турында сөйләде. Мәктәп контентын эшләгәндә, университет укытучылары тарафыннан якынча 7000 күнегү, 300 видеосюжет, 10000 аудиофайл, 7000 фотосурәт тупланган. Хәзерге вакытта онлайн мәктәптә якынча 10000 укучы татар теле өйрәнә.

Шулай ук рус теленә өйрәтү буенча «Русское слово» проекты эшләнеп килә. Бу проект белән Г.В.Садыйкова таныштырды. Беренче чиратта, проект чит ил студентларына рус телен өйрәтүне күз уңында тота. Проект әзерлеге төрле дәрәҗәдәге кешеләр өчен яраклы булачак. Бу проект нигезендә укучының менталитетына туры китерелгән программалар эшләнәчәк, ул төрле аудиториягә юнәлтеләчәк. Проект рус телен төрки халыкларга өйрәтү юнәлешендә әзерләнәчәк, моңа исә университетта көнчыгышны өйрәнү фәненең югары үсеш алуы, гасырлар буе тупланган күпьеллык тәҗрибә, тиешле кадрлар җирлек булып тора.

А.А.Климов һәр ике проект турында да уңай фикерләрен әйтте, җиң сызганып, эшне дәвам итәргә киңәш итте, РФ Мәгариф һәм фән министры Д.В.Ливанов белән очрашу вакытында бу проектлар турында сөйләячәген хәбәр итте.

• Халык җәүһәрләре

Музей төне. Нәрсә соң ул? 17 май төненнән 18 май көненә булган Музейлар төне. Төн дигәч, бик сәер тоелса да, бу – бик тә кызыклы, үзенчәлекле, ә, иң мөһиме, мавыктыргыч чара.

# Муса Җәлилдә «кунакта»

**Эльвина НӘҖИПОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Казан каласында нинди генә музейлар юк?! Гадәттә, музейга көн яктысында йөрибез. Ә бу көнне музейлар белән төнлек әйләнәсендә танышырга мөмкин. Нәкъ менә шул төндә яңа буын җыены «Калеб» М.Җәлилнең музей-фатирында иҗатчылар белән очрашу үткәрде. Ул яңа шигырьләр, җыр-моң, җылы аралашуларга бай булды. «Калеб» не җитәкләүче Гүзәл Сәгыйтова белән М.Җәлилнең музей-фатиры мөдире Нәзирә ханым Фәттахова бу чараны оештыру өчен зур көч куйганнар. Кичәне яшь шагыйрә Йолдыз Миңуллина алып барды. Әле шушы көннәрдә генә Белла Ахмадуллина премиясенә лаек булган шагыйрә Луиза Янсуар яшь иҗатчыларның иҗатын бәяләде, үзенең шигырьләре белән куандырды. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең «Әллүки» иҗат берләшмәсе әгъзалары да үз шигырьләрен укыдылар. Казан консерваториясендә белем алучы студентлар, төрле уен коралларында уйнап, М.Җәлил сүзләренә язылган җырларны башкарып, барлык тамашачыларны таң калдырды.

Кичәдән соң Нәзирә ханым барлык чарада катнашучылар өчен музей буенча экскурсия оештырды. Аннары очрашу чәй өстәле янында дәвам итте. Кайчандыр Муса Җәлил гаиләсе белән чәй эчеп утырган өстәл артында аралашып утыру зур горурлык хисләре уятты.

• Сәяхәттән кайткач

Рания Гыйрфанова – КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 4 курс студенты. Агымдагы уку елында ул ярты ел буе дәресләргә йөрмәгән… Шаяртам, әлбәттә, Рания сәбәпсез дәрес калдыручылардан түгел, ул быел Кытайда Хунань провинциясенең Чанша шәһәрендә стажировка үтеп кайтты. Без дә аның белән тәэсирләрен уртаклашырга булдык. Кем белә, бәлки, газета укучыларыбыз арасында да Кытайга барырга теләге булган кешеләр бардыр.

# Татарча да яхшы бел, кытайча да…

**Лилия ЯКУПОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



**– Рания, Кытайга бару максатыңны әйтеп китсәң иде?**

– Кытайга баруымның максаты, әлбәттә, Кытай телен өйрәнү, аны тиешле дәрәҗәдә үзләштерү иде. Казанда мөмкинлекләр күп булса да, әлеге телне Кытай мохитендә өйрәнү күпкә тизрәк һәм кызыграк. Дөньяны танып белү, чит илне күрү минем өчен шулай ук бик мөһим иде.

**– Әйткәнемчә, газета укучыларыбыз да кызыксына торганнардыр. Син сәяхәткә нинди программа буенча киттең?**

– Мин бер ел буе Конфуций институтының кичке курсларына йөрдем. Конфуций институтының җитәкчесе миңа Кытайга бару өчен грант отып карарга тәкъдим итте. Грант отуның төп шартлары – Конфуций институтында 72 сәгать уку һәм HSK халыкара имтиханын тапшыру иде. Кытай телен күпмедер дәрәҗәдә белү шулай ук кирәк, чөнки мотивацион хатларны кытай телендә язарга туры килде.

**– Рания, син – бик кызыксынучан кеше. Кытайда, укудан тыш, тагын нәрсәләр белән шөгыльләндең?**

– Бу минем чит илгә беренче тапкыр чыгуым иде, шуңа күрә барысы да яңа, кызык иде. Октябрь аенда безгә 1 атна ял бирделәр һәм без Шанхай, Пекин шәһәрләренә барып кайттык. Кытай стенасын, Мао Цзэдун һәйкәлен, Шанхайның биек йортларын күрү, һәр шимбә саен салют карау, Кытай мәдәнияте һәм бәйрәмнәре белән танышу онытылмаслык хисләр калдырды. Чит илдән килгән студентлар өчен еш кына төрле чаралар үткәрелде. Мисал өчен, мин иероглифлар язу бәйгесендә катнаштым.

**– Кытайдагы укыту системасы турында ниләр әйтә аласың? Безнең укыту системасыннан аермасы, охшаш яклары бармы?**

–Минемчә, әлеге ике бер-берсенә охшамаган системаны чагыштыру бик үк дөрес тә булмас. Ләкин Кытайдагы уку шартларыннан, укытучылардан, аларның укыту ысулларыннан мин канәгать калдым. Укытучылар һәр дәрескә презентация әзерлиләр, материалны төпле итеп аңлаталар. Дәрес вакытында игътибар һәрбер студентка тиешле дәрәҗәдә бирелә. Кытайдагы укытучылар да дәрескә соңга калган, өй эшен эшләмәгән студентларны яратмыйлар.

**– Кытайдагы татарлар белән күрешмәдеңме? Гомумән, Кытай кешеләре белән аралашудан алган тәэсирләрең?**

– Ни үкенеч, Кытайдагы татарлар белән мин аралаша алмадым, чөнки күпчелек татарларның яшәү урыннары Хунань провинциясеннән ерак. Ләкин мөселманнар күп иде. Мин яшәгән шәһәрдә мәчет тә бар. Кызганычка каршы, татарларның кем икәнлеген кытайлар белмиләр диярлек. Алар белән аралашканда да татар халкының кем икәнлеген аңлатырга туры килде. Кытай кешеләренә килгәндә, алар бик яхшы тәэсир калдырды. Чит илдән килгән кешеләрне яратып каршы алалар. Бигрәк тә Аурора кыяфәтле кешеләргә мөнәсәбәтләре яхшы. Безнең белән һәрвакыт фотога төшәргә сорыйлар һәм еш кына комплиментлар әйтәләр.

**– Рания, әлеге сәяхәтең вакытында үзең өчен нинди яңалыклар ачтың, уңай яклар таптың?**

– Мин укыган төркемдәге студентларның барысы да төрле илләрдән килгәннәр иде: Корея, Бразилия, Мексика һ.б. Алар белән аралашу, кайвакыт бер-беребезне үзебез сөйләшкән телгә өйрәтү, мәдәниятебез, илебез турында сөйләү, бергәләп кытай телен өйрәнү бик кызык булды. Кытай теле без уйлаганнан да авыр булып чыкты. Әлеге телдә тоннарны дөрес итеп куллану мөһим. Кайвакыт, мине аңласыннар өчен, бер үк сүзне дүрт-биш тапкыр төрле тоннар белән кабатлый идем. Кытай дусларыма түземлелекләре өчен рәхмәт.

**– Кытайдан кайтуыңа инде ярты еллап вакыт узып бара. Сагындырамы, тагын барыр идеңме?**

– Сагындыра, тагын барыр идем. Ләкин башка шәһәрләрне дә күрәсем килә. Хәзерге вакытта мөмкинлекләр күп һәм алардан файдаланырга кирәк дип саныйм.

**– Әңгәмәң өчен зур рәхмәт, Рания! Киләчәктә дә сиңа телләр өйрәнүдә, укуыңда уңышлар телибез. Максатларыңа ирешергә язсын!**




• Халәт



# Уйларымда мәктәп еллары…

**Адилә ГЫЙЛАЕВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Эх, мәктәп еллары… Рәхәт тә, куанычлы да, ваемсыз да, тынгысыз да мәктәп еллары. Моның шулай икәнен бары тик мәктәпне тәмамлап, туган яктан аерылып киткәч, белем алган мәктәбеңнән читтә булганда гына аңлыйсың икән.

Мәктәп еллары һәркем тормышында зур урын алып тора, чөнки ул еллар – балачак еллары. Ә балачак елларын әле беркемнең дә читләтеп үтә алганы юк. Шуның белән бергә, ул еллар – кешенең шәхес буларак формалашкан вакыты да. Олыгая барган саен, ул елларның һәр мизгеле үзәкләрне өзеп хәтерләрдә кабат яңарачак әле.

Ак бантиклар тагып, кулларына чәчәк бәйләме тоткан бала мәктәп дигән дөньяның ишеген тәүге тапкыр ачып керә. Бу – һәркем күңелендә гомернең соңгы көннәренә кадәр уелып калган мизгелдер. Сабый күңеленә ачкыч таба белгән, балаларны намуслы, мәрхәмәтле булырга өйрәткән, һәрберебезгә белем алуга аңлы караш, үз көченә ышаныч уята алган беренче укытучыларыбызны онытырга һич хакыбыз юк. Беренче укытучымның кулдан тотып авыш сызыклы дәфтәр битенә хәреф язарга, шул хәрефләрне кушып укырга өйрәткәне хәтеремдә уелып калды. Беренче укытучы… Кеше тормышында бу илаһи затлар бердәнбер һәм мәңгелек булалар. Гади генә сүзләр белән «абый», «апа» дип йөртелүче мөгаллимнәр – балаларга белем бирүче генә түгел, изгелек орлыклары салучы мәрхәмәт ияләре дә.

Беренче кыңгырау, беренче укытучы кебек кеше гомерендә онытылмаслык булып, уелып калган мизгел – Соңгы кыңгырау бәйрәме дә күз алдыннан китми.

Мәктәпләрдә чыгарылыш сыйныф укучылары өчен шатлыклы да, шул ук вакытта моңсу да булган бәйрәм көннәре якынлаша. Алар һәрберсе үз тормышында кирәк булачак һөнәрләрне сайлап өлгергәндер. Алар өчен дә тиздән, кыңгыраулы мәктәп еллары үзенең ыгы-зыгысы, күңелле мизгелләре, борчу-мәшәкатьләре белән артта калыр. Соңгы кыңгырау ул, урта мәктәпне тәмамлап, зур тормышка юл алган егетләр һәм кызларны алдагы көннәрнең гаҗәп матур да, сокландыргыч һәм авыр да булачагын искәртеп тора кебек.

Мәктәп бусагасыннан атлап керү безнең һәрберебез өчен дә зур шатлык булып калсын, алган белемнәрнең, аны өләшкән укытучыларның, белем алу өчен мөмкинлекләр булдырган мәктәпләрнең кадерен белеп яшик. Югары белемнең нигезе – үзең укыган мәктәптә, ә институт шул белемне тулыландыра гына. 40 еллык тарихы булган үз мәктәбемне теләсә кайсы мәктәпләрдән өстен күрәм. Еллар узар, безнең арадан да икътисадчылар, агрономнар, укытучылар чыгар. Менә шул чакта без, иң башта, горурланып, мин Аксар урта мәктәбендә укыган идем дип әйтербез!

• Игътибар! Конкурс!

«Дарелфөнүн» газетасы редакциясе КФУның «Каләм балкышы» студентлар газетасы конкурсы дәвам итә.

**Эшләрегезне 27 майга кадәр редакциягә китереп бирә яки электрон почтага җибәрә аласыз.**

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.